Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2020 Менделеевск ш. № 621

«2019 - 2021 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
физик культураны һәм спортны үстерү»
район максатчан программасына
үзгәрешләр кертү турында

«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» район максатчан программасының программа чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 838 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» район максатчан программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. III бүлек 2 нче абзац «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне җайга салу» үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Физик культура һәм спорт» бүлеге буенча:

2021 ел - 61 268, мең сум, шуларның 500,0 мең сумы чараларга;

Бюджеттан тыш МБУ ОК «Нептун» - 1 500,0 мең сум, МБУ «СШ «Айсберг» - 2 000,0 мең сум, МБУ «СШ «Батыр» - 60,0 мең сум, МБУ «КСШ «Фаворит» - 60,0 мең сум».

1.2. VI бүлекнең 1 пункты «программа чаралары исемлеге» Программасына түбәндәге эчтәлекле 1.6 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.6 | ТР МБ территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура- | МБУ «СШ «Батыр» | 2020 | ТР бюджеты<br><br>Җирле бюджет | | 500,13<br><br>5,0 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, модульле чаңгы базаларын оператив идарә итү хокукында калдыруга бәйле рәвештә муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан муниципаль биремне финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә | | | | | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.И. Ямалеевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В. Метальников